




№66
Октябрь,
2021 ел

Яр Чаллы шәһәренең “52 нче урта белем бирү мәктәбе” газетасы



# Яңа уку елы белән, дуслар! Балачакның иң матур бер мизгеле – 1 Сентябрь иртәсе

Әй, мәктәбем, хәерле юл теләп,
Белем ишекләрен ачтың син.
Юлыбызны гүзәл итәр өчен,
Якты маяк булып балкыйсың

Менә балаларның зарыгып, көтеп алган җәйге каникуллары да тәмамланды. Барлык мәктәпләрдә дә беренче кыңгырау чыңлады. Көмеш кыңгырауның чыңлавы, саф күңелле сабыйларны, үсмерләрне һәм әти-әниләрне сөендереп, 1 сентябрь – Белем бәйрәме ишек какты. Бу көннәрдә өлкәннәр дә, зур дулкынлану хисләре кичереп, мәктәп сукмаклары белән бәйле хатирәләрне, хөрмәт хисе белән үзенә хәреф таныткан, кулыннан тотып язарга өйрәткән беренче укытучысын, мәктәбен, сыйныфташларын сагынып искә алды..

Әйе, бала мәктәптә матурлыкка омтыла, якты киләчәгенә кул сузып бара. Алдында биек үрләр, шул үрләрне яулый алса гына ул бәхетле булачак. Аңа шушы үрләрне яулауда, белем алуда укытучы ярдәмгә килә.

Укучылар, сезне алда күңелле вакыйгаларга бай уку елы көтә. Белем үрләренә армый-талмый атлап, безнең буынга лаеклы алмаш булып үсегез.

Барлык укучыларның да һәрвакыт белемгә, яңалыкка, камиллеккә омтылып яшәүләрен, яңа уку елы яңа иҗади уңышлар, саулык-сәгадәт, бәхетле һәм имин көннәр, күңел тынычлыгы, иҗади җиңүләр, рухи күтәренкелек, яхшы кәефләр генә теләп калабыз.




Белем бәйрәмен мәктәп директоры Дамир Денислам улы Нуриәхмәтов башлап җибәрде.Ул укучыларны һәм әти-әниләрне яңа уку елы башлану белән тәбрик итте. Укучыларга белем үрләрен яулауда, алга куйган максатларына ирешү өчен, армый талмый тырышып укып, зур уңышларга ирешүләрен, һәм исәнлек-саулык, иминлек, яхшы кәефләр теләде. Аннан соң сүз Автозавод районы ветераннар советы председателе Л.М.Ходорковскаяга, килгән башка кунакларга, укучыларга бирелде.



Хәерле юл сезгә, укучылар!

## *Мәктәбебез тормышыннан...*

Бу уку елында безне яңа директор - Дамир Денислам улы Нуриәхмәтов каршы алды. Без Камилә һәм Руслан “Чишмә”газетасының яшь хәбәрчеләре буларак Дамир Денислам улы Нуриәхмәтов белән якыннан танышу өчен, аннан интервью алырга булдык.



52 нче мәктәп директоры
Дамир Денислам улы Нуриәхмәтов



5б сыйныф укучылары
Логинов Руслан
Валиахметова Камилә

**Дамир Денисламович! Сез ни өчен укытучы һөнәрен сайларга булдыгыз?**

-Һәр кеше дә һөнәрле булырга тиеш,миңа да киләчәк һөнәремне сайларга кирәк иде.Инглиз теленә булган мәхәббәтем,мина укытучылык һөнәрен сайларга этәргеч булды. Бу максатымны тормышка ашыру өчен, мин педагогик университетның чит телләр факультетына укырга кердем.

**- Инглиз телен кайда өйрәндегез?**

- Мәктәптә минем өчен күп фәннәр җиңел бирелде, ләкин аеруча икътисад, хокук, тарих һәм инглиз телләре күбрәк ошый иде. 10-11 сыйныфларда Яр Чаллы шәһәренең Пушкин исемендәге 78 нче лицейның гуманитар юнәлешендәге сыйныфында белем алдым. Безгә атнага 8 сәгать инглиз теле дәресе керә иде. Шул сәбәпле мин университетка җиңел кердем.

**- Гаиләгездә укытучылар бармы?**

- Әйе. Бер туган апам да 50 нче мәктәптә укытучы булып эшли.

**Беренче укытучыгыз кем иде?**

Беренче сыйныфка шәһәрнең 47 нче мәктәбенә укырга кердем. Беренче укытучым Ирина Александровна Колоколова иде.

**Мәктәптә ничек укыдыгыз?**

Мәктәптә мин дүртле һәм бишле билгеләренә генә укыдым.

**- Гаиләгез зурмы?**

Минем гаиләм бик зур түгел. Мин өйләнгән, ике улым бар. Тормыш иптәшем шәфкать туташы булып эшли.

**- Хезмәт юлыгызны кайсы мәктәптә башладыгыз?**

Хезмәт юлымны мин 66 нчы мәктәп — интернатта инглиз теле укытучысы булып башладым, аннары 40 мәктәптә

2 ел укыттым. 2010 елдан 2021 елга кадәрле 22 нче мәктәптә тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләдем.

**Сезнең хобби?**

- Буш вакытым булганда мин спорт белән шөгыльләнергә яратам. Кыш җиткәч чаңгыда шуам, җәй көне йөгергә яратам.

**- Күптәннәме?**

- Мин чаңгыда биш ел гына йөрим, йөгерү белән 15 елдан артык шөгыльләнәм.

**- Ирешкән уңышларыгыз ?**

Минем зур уңышларым булмады. 10-15 ел элек марафонда йөгерүдә катнаша идем.Моның өчен хәзер вакыт җитми.

**- Ял итәргә вакыт табасызмы?**

Минем бер генә көн ялым бар. Бу якшәмбе көне. Бер көн тулысынча ял итәр өчен җитми. Бу көнне гаиләм белән үткәрергә тырышам.

**Сезгә эшегездә зур уңышлар, исәнлек-саулык теләп калабыз. Безнең өчен вакыт тапканыгыз,әңгәмәгез өчен зур рәхмәт.**

# Җәйге яллар...

Көтеп алган җәйге яллар узып та китте. Кемдер авылда, кемдер шәһәрдә. Кемдер сәяхәттә булды. Кемнәрдер иҗат белән шөгыльләнде. 6б сыйныфы укучысы **Липатова Аделина** Россиякүләм гимнастика ярышында 1нче урын яулап кайтты.
Җәй, әлбәттә, үзенең матур сабантуйлары белән дә ялларыбызны бизәми калмады, аеруча үзебезнең егетләребез көрәшкә чыкканда. 8а сыйныфы укучысы **Хәйруллин Азамат** үзенең яшьтәшләре арасында Чаллы сабантуенда 3 нче урынны




5б сыйныфы укучысы **Валиахметова Камилә** быел да XII Республикакүләм АРТ Фестивалендә сынлы сәнгать һәм дизайн буенча беренче урын алды.



6б сыйныф укучысы **Хәсанова Айсылу**, Республикакүләм “Беренче адымнар” яшь башкаручылар фестиваль конкурсында катнашып, 1нче дәрәҗәдәге, Казан шәһәрендә “Балалы солянка” телевизион (ТМТV) тапшыруын да катнашып, дипломга лаек булды.



## *Әлифба алды куллар. Без инде хәзер зурлар...*

Тәүге тапкыр хәреф танырга, язарга, ә соңыннан укырга, санарга өйрәнү – беркемнең дә күңеленнән җуелмыйдыр мөгаен. Ә боларны өйрәтүче, белем дөньясына алып керүче башлангыч сыйныф укытучыларыбыз. Күп еллар безнең мәктәптә укытучы Садриева Гөлчәчәк Нәгимулла кызы быел да 1нче сыйныф укучыларын тәүге китаплары-”Әлифба” белән таныштырды.



## *Яраткан укытучым*

Сүзем иң яраткан укытучым, сыйныф җитәкчем Алия Илфак кызы Корбанова турында. Ул республикабызның



гүзәл төбәге—Актанышта туган. Чаллы дәүләт педагогика университетында югары белем алган. Татар теленнән халыкара олимпиада җиңүчесе, Саҗидә Сөләйманова, Клара Булатова, Каюм Насыйри исемендәге премияләр лауреаты.
Ул мәктәбебездә татар теле һәм рус теле укытучысы булып эшли. Бернчә ел рәттән “Иң аңлаучан укытучы” номинациясендә җиңү яулый.
**-Алия апа, ни өчен укытучы һөнәрен сайладыгыз? Һәм ни өчен нәкъ татар теле мөгаллиме булырга уйладыгыз?**
– Бу һөнәрне сайлавыма беренче укытучым Эльмира апа сәбәпче булды. Мин аңа карап гел соклана идем
Минем дә аның кебек изге күңелле, яхшы укытучы буласым килде. Туган телем – татар теленә мәхәббәт, аның киләчәге өчен борчылу мине татар филологиясенә китерде.
**– Студент вакытта ук үзегезне талантлы һәм максатчан, булдыклы шәхес итеп күрсәткәнсез, халыкара бәйгеләрдә җиңүләр яулагансыз. Төрле мәктәпләрдән тәкъдимнәр булгандыр. Ни өчен Чаллыны һәм 52 нче мәктәпне сайладыгыз?**
– Мин Чаллыны яратам. Монда яшьләр өчен, үз талантыңны күрсәтү, ачу өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Шуңа күрә, шәһәрнең 52 нче мәктәбенә татар теле укытучысы кирәк дигән сүзне ишеткәч, эшләргә килдем.

**Татар теле мөгаллиме булу авырмы?**
Яшермим, җиңел түгел. Мин һөнәрем буенча рус теле укытучысы да. Рус теленнән белем бирергә күпкә җиңелрәк. . Бу фәннән балалар имтихан бирә, бөтен уку йортларында да укытыла, шуңа күрә аларның ул предметны укырга теләге бар, теләк булгач, алар белән эшләве рәхәт. Ә татар теленнән имтиханнар бирәсе юк, күп кенә укучыларның татар телен өйрәнәсе, укыйсы килми. Аларны кызыксындыру өчен, яңа чаралар уйлап табарга, гел яңалык эзләргә, бик нык тырышырга туры килә.

**– Хәзерге белем бирү системасында нинләр үзгәртер идегез?**
– Безнең әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез белем алгантрадицион системаны кире кайтарыр идем. Элек ничек булды да, хәзер ничек булды, чагыштырырга була. Элек бик күп фәннәрдән дәүләт имтиханы бар иде.
Шуңа ныклы әзерләнеп, һәр фәнне өйрәнеп, укытучы каршына чыгып утырып сөйлисең, аңлатасың. Менә бу чын белем тикшерү иде!

**– Татар теле укытучысы буларак, ирешкән уңышларыгыз турында да сөйләп үтегез әле, Алия апа.**
– Мин – «Безнең яңа укытучы- 2017» гранты җиңүчесе. Берничә ел рәттән инде Айдар Хәлим, Туфан Миңнуллин исемендәге региональ укуларда призлы урыннар яулыйм. Ризаэддин Фәхреддин, Кадыйр Сибгатуллин исемндәге конференцияләр лауреаты.
Иң зур уңышларны миңа укучыларым китерә. Узган ел татар әдәбиятыннан республика олимпиадасында укучым призер булды.

**– Сез социаль челтәрләрдә дә актив. Матур итеп шигырьләр сөйлисез. Бу – күңел ихтыяҗымы, ялмы? Шигъриятькә мәхәббәт нидән?**
– Иҗатка, шигърияткә мин кечкенәдән гашыйк. Хәтерлим, бәләкәй чагымда ук авыл мәдәният йортының сәхнәсенә чыгып шигырьләр сөйли идем. Шигырьләр уку — ул минем күңел ихтыяҗы.
Берәр җирдә матур, эчтәлекле шигырь күрәм дә, ул күңелгә шундый якын була, аны кешеләргә дә җиткерәсе килә башлый. Сөйләмичә, социаль челтәрләргә куймыйча булдыра алмыйм.

**– Укытучы һөнәрен сайларга җыенучы яшьләргә нинди киңәшләр бирер идегез соң?**
– Үзеңнең һөнәрең буенча югары дәрәҗәдәге белгеч булыр өчен, бөтен мөмкинлекләрне файдаланырга. Беренчедән, фәннәрне яхшы үзләштерергә, җай булган саен, түгәрәкләргә йөрергә, фәнни-тикшерү эшләрендә катнашырга, һәрвакыт үзеңне укытучы булыр өчен әзерләргә.

**– Ә үзегезгә мәктәп эше берәр сабак бирдеме?**
– Мәктәптә эшләү мине җиде кат үлчәп, бер кат кисәргә, сабыр булырга өйрәтте.
– Уңышлар сезгә, Алия апа!
Әңгәмәдәш – 9 нчы а сыйныфы укучысы Якупова Зәринә

**Редактор Руслан Логинов**
**Җаваплы сәркатип Камилә Валиахметова**
**Кординатор Илфания Нурутдинова**

## Тиздән укытучылар көне

Иң беренче мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр безнең янәшәбездә һәрчак яраткан укытучыларыбыз атлый. Алар безне белем дөньясына алып керә, яхшыны яманнан аерырга , хезмәтне яратырга өйрәтә.Сезнең барыгызныда укытучылар көне белән ихлас күңелдән котлыйбыз. Авыр, әмма җаваплы һәм мактаулы эшегездә зур уңышлар, корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, иксез-чиксез сабырлык, гаилә бәхете телибез. һәр таңны саусәламәт каршылагыз, һәр яңа көн сезгә сөенеч, шатлык, бәхетләр генә алып килсен, замана авырлыклары, күңел төшенкелеге сезне читләтеп үтсен.

***Укытучыма.***

**Баласыдай якын күрә**
**Укучының һәрберсен.**
**Йөрәге аша кичереп,**
**Аңлата ул дәресен.**
**Укытучы кояш кебек**
**Тора һәрчак елмаеп.**
**Укытучы булган өчен**
**Аңа һәйкәл куярлык.**
**Ача безгә бу дөньяның**
**Бик күп яңа серләрен.**
**Гел тыңлыйсы килеп тора**
**Аның матур сүзләрен.**




**Безнең адрес: 423827,**
**Яр Чаллы шәһәре,**
**Яңа шәһәр,52/36,52 нче**
**татар гомуми белем**
**бирү мәктәбе**
**Телефон:59-36-88**
**Факс:(8552)**
**59-36-90**
**Эл.почта:**
**Sch52_ chelny@ mail.ru**
**Без Вебта:http://**
**Edu.tatar.ru/n_chtlny/**
**Sch52**